**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ШӘТКЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫНЫҢ**
**өченче чакырылыш чираттан тыш утырышы**
**карары**

**2018 елның 30 ноябре** **№ 98**

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Шәтке авыл җирлеге Советының “Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының Шәтке авыл җирлеге территориясендә физик затлар милкенә салым турында”гы 2014 елның 24 ноябрендәге 120 нче санлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге, “Россия Федерациясе Салым кодексы 52 нче статьясенең беренче һәм икенче өлешләренә үзгәрешләр кертү турында”гы 2018 елның 03 августындагы 334-ФЗ санлы Федераль законга туры китереп, Шәтке авыл җирлеге Советы карар кабул итте,

1. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Шәтке авыл җирлеге Советының “Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Шәтке авыл җирлеге территориясендә физик затлар милкенә салым турында”гы 2014 елның 24 ноябрендәге 120 нче санлы (2015 елның 08 маендагы 145 нче санлы, 2015 елның 12 октябрендәге 3 нче санлы, 2018 елның 12 апрелендәге 69 нчы санлы редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1.түбәндәге эчтәлектәге 3.2 пункты өстәргә:

“3.2. Түбәндәге физик затларны милек салымыннан азат итәргә:
3.2.1. 18 яшькә кадәрле дүрт һәм аннан да күбрәк балалары булганнарны;
3.2.2 әлеге пунктның 3.2.1 пунктчасының күрсәтелгән гражданнарның балаларын;
3.2.3. тулы дәүләт тәэминатында булмаган инвалид балаларның ата-аналарын (уллыкка/кызлыкка алучылар, опекуннар, тәрбиягә алучылар).
Салымга ташламалар түбәндәге объектларга каралган:
1) фатир, фатирның бер өлеше яки бүлмә;
2) торак йорт яки торак йортның бер өлеше.

Салымга ташлама, салым түләүченең теләге буенча, гаилә карамагындагы бер генә объектка бирелә.

Салымга ташлама Шәтке авыл җирлеге территориясендә даими яшәүче салым түләүченең милкендә булган һәм эшмәкәрлек эшчәнлеге максатларында

кулланылмаучы объект өчен тиешле салым күләмендә бирелә.

Салымга ташламага хокукы булган физик затлар салым органына салымга ташлама бирү турында гариза яза, шулай ук салым түләүченең салымга ташламага хокукын раслаучы документлар тапшыра ала.

Салымга ташламага хокукны раслаучы документлар булып әлеге төр салым түләүче физик затның шәхесен раслаучы документ, шулай ук аның исеменә бирелгән күп балалы гаилә таныклыгы, яки өч һәм аннан да күбрәк балаларның туу турындагы таныклыклары тора.

Салымга ташламалы объектны сайлавы турында салым түләүче салым органына салым чоры булган елның 1 ноябренә кадәр хәбәр итәргә тиеш. Шушы вакыттан күрсәтелгән объектларга салымга ташлама кулланыла башлый.

2.Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм Интернет челтәренең Шәтке авыл җирлеге рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Карарның 1 пунктында күрсәтелгән 3.2 пункты рәсми бастырып чыгарганнан соң бер ай үткәч кочено керә һәм 2018 елның 1 гыйнварыннан гамәлдәге хокукый мөнәсәбәтләргә кагыла.

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Шәтке авыл җирлеге башлыгы Ф.Г.Кадыйров

кулланылмаучы объект өчен тиешле салым күләмендә бирелә.

Салымга ташламага хокукы булган физик затлар салым органына салымга ташлама бирү турында гариза яза, шулай ук салым түләүченең салымга ташламага хокукын раслаучы документлар тапшыра ала.

Салымга ташламага хокукны раслаучы документлар булып әлеге төр салым түләүче физик затның шәхесен раслаучы документ, шулай ук аның исеменә бирелгән күп балалы гаилә таныклыгы, яки өч һәм аннан да күбрәк балаларның туу турындагы таныклыклары тора.

Салымга ташламалы объектны сайлавы турында салым түләүче салым органына салым чоры булган елның 1 ноябренә кадәр хәбәр итәргә тиеш. Шушы вакыттан күрсәтелгән объектларга салымга ташлама кулланыла башлый.

2.Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм Интернет челтәренең Шәтке авыл җирлеге рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Карарның 1 пунктында күрсәтелгән 3.2 пункты рәсми бастырып чыгарганнан соң бер ай үткәч кочен кераә һәм 2018 елның 1 гыйнварыннан гамәлдәге хокукый мөнәсәбәтләргә кагыла.

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Шәтке авыл җирлеге башлыгы Ф.Г.Кадыйров